ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2023 елның 30 гыйнвары** **Чистай шәһәре** **№ 31**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «2022-2023 елларга Чистай муниципаль районы торак фондында торак урыннардан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү), торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен раслау турында» 2022 елның 5 июлендәге 771 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156. 158 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта гомуми милекне тиешле сыйфатта карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәт күрсәтүләр һәм эшләр башкару очракларында торак бинаны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы РФ Хөкүмәте карары , «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауга минималь кертем күләмен билгеләү турында» 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 30 декабрендәге 1484 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «2022-2023 елларга Чистай муниципаль районы торак фондында торак урыннардан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү), торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен раслау турында» 2022 елның 5 декабрендәге 771 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. карарның кушымтасында «Торак бинаны капиталь ремонтлау» 2 нче юлында «Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда)» 5 нче баганасында «6,38» саннарын «6,95» саннарына алмаштырырга.
2. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисад бүлегенә әлеге карарны «Чистай хәбәрләре» газетасында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук Чистай муниципаль районының

рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны икътисадый мәсьәләләр буенча Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов